СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

24.09.2019            с.Соболевское            № 75-308

Соболевский  авыл җирлеге территориясендә
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Соболевский авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Соболевский авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 11.09.2019 ел, № 57-268 карары, Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»  12.09.2019 ел  №  33 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге
карар чыгарды:

1. 2019 елның 17 ноябренә Соболевский авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Карамышиха авылында чишмәне төзекләндерү;

Соболевский авылында су башнясы территориясен койма белән әйләндереп алу ;

- урамнарны яктырту системасын ремонтлау, Соболевское авылында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге
Башлыгы О.Н.Майорова